# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм
Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү
турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

2004 елның 29 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 пунктындагы дүртенче абзацында "субвенцияләр" сүзен "субсидияләр" сүзенә алмаштырырга;
2) $20^{1}$ статьяның 5 пунктында:
а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Оператив идарә итү хокукына нигезләнгән дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесенә, автоном һәм бюджет учреждениесенә бюджет инвестицияләрен бирү дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесенең, автоном һәм бюджет учреждениесенең оператив идарә итү хокукындагы төп чаралары хакының тиешенчә артуына китерә.";
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән бюджет инвестицияләрен бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.";
3) 23 статьяның 1 пунктындагы дүртенче абзацында "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;
4) $23^{1}$ статьяның 1 пунктындагы дүртенче абзацында "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;
5) 44 статьяда:
а) 2 пунктта "субвенцияләрдән" сүзеннән соң ", шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен

гамәлгә ашыруга Россия Федерациясенең инвестицияләр фонды акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләргә бирелә торган субсидияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан" сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктта "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан" сүзләренә алмаштырырга, "субвенцияләрдән" сүзеннән соң ", шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясенең инвестицияләр фонды акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләргә бирелә торган субсидияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан" сүзләрен өстәргә;

в) 4 пунктның беренче абзацында "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан" сүзләренә алмаштырырга, "субвенцияләрдән" сүзеннән соң ", шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясенең инвестицияләр фонды акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләргә бирелә торган субсидияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан" сүзләрен өстәргә;

6) $44^{11}$ статьяда:

а) 1 пунктта "күчерергә тиеш" сүзләрен "күчерәләр" сүзенә алмаштырырга, "муниципаль район бюджетына" сүзләреннән соң "муниципаль район уставында билгеләнгән очракларда" сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта "тәртибе" сүзеннән соң "(методикасы)" сүзен өстәргә;

в) 3 пунктта "шушы муниципаль районның тиешле җирлекләре өчен җан башына йә муниципаль хезмәтләрне кулланучыга исәпләгәндә бердәм норматив буенча" сүзләрен "шушы муниципаль районның барлык җирлекләре өчен билгеләнгән бердәм методика буенча" сүзләренә алмаштырырга;

7) 49 статьяның утыз өченче абзацында "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;

8) 50 статьяның 3 пунктындагы беренче абзацында "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;

9) 61 статьяның 4 пунктында:

а) уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) унбишенче абзацта "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;

10) 64 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"64 статья. **Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында карау функцияләрен бүлү**

Әлеге Кодекс таләпләрен үтәп кертелгән чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына, закон чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына җибәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын бюджетны карау өчен җаваплы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетына (алга таба – Бюджет комитеты) җибәрә һәм бюджет проектының һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектының аерым бүлекләрен һәм бүлекчәләрен карау буенча өстәмә комитетларны (алга таба – өстәмә комитетлар) билгели.";

11) 67 статьяда "Президиумы тарафыннан билгеләнә торган" сүзләрен "Рәисе тарафыннан билгеләнә торган" сүзләренә алмаштырырга, "30 көннән дә соңга калмыйча" сүзләрен "30 көннән дә артыграк булмаган вакытта" сүзләренә алмаштырырга;

12) 68 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"68 статья. **Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан билгеләнә торган вакытка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары күрсәтелгән закон проекты буенча бәяләмәләр һәм тәкъдим ителгән закон проектын кабул итү яисә кире кагу турында тәкъдимнәр, шулай ук закон проекты буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр әзерлиләр һәм аларны Бюджет комитетына җибәрәләр.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларның бәяләмәләре нигезендә Бюджет комитеты күрсәтелгән закон проекты буенча җыелма бәяләмә әзерли.";

13) 69 статьяда "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты" сүзләрен "Бюджет комитеты" сүзләренә алмаштырырга;

14) 72 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнгән, әмма күрсәтелгән закон проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң 30 көннән дә артыграк булмаган вакытта карый.

Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар үзләренең төзәтмәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә торган вакытта Бюджет комитетына җибәрәләр.

Бюджет комитеты төзәтмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә карый һәм тәкъдим ителгән төзәтмәләргә экспертиза үткәрә, аны исәпкә алып, төзәтмә буенча Бюджет комитетының карары кабул ителә.";

15) 73 статьяда "15 көннән дә соңга калмыйча" сүзләрен "15 көннән дә артыграк булмаган вакытта" сүзләренә алмаштырырга;

16) 77 статьяның 3 пунктында:

а) бишенче абзацта "бюджет учреждениеләренең" сүзләрен "казна учреждениеләренең" сүзләренә алмаштырырга;

б) сигезенче абзацта "субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны" сүзләрен "субвенцияләрне, башка бюджетара трансфертларны, физик һәм юридик затлардан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәрне" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә банк депозитларында бюджет акчаларын урнаштырган очракта;";

г) унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга;

д) түбәндәге эчтәлекле яңа уникенче абзац өстәргә:

"дәүләт учреждениеләренең тибын һәм дәүләт унитар предприятиеләренең оештыру-хокукый рәвешен үзгәрткән очракта.";

е) уникенче абзацны унөченче абзац дип санарга;

17) $80^2$ статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче абзацта "бюджет учреждениесенең" сүзләрен "казна учреждениесенең" сүзләренә алмаштырырга, "бюджет учреждениесе" сүзләрен "казна учреждениесе" сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды белән идарә итү органы булган казна учреждениесенең бюджет сметасы шул органның җитәкчесе тарафыннан раслана.";

б) 2 пунктта:

беренче абзацта "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга, "мөмкин" сүзен "тиеш" сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта "бюджет" сүзен "казна" сүзенә алмаштырырга;

18) 93 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Бюджет үтәгәндә бюджет турындагы закон (карар) белән расланган керемнәрдән тыш фактта артыграк алынган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән аларның агымдагы финанс елы башына кулланылмый калган калдыклары, агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы законга (карарга) үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатлары өчен бюджет чыгымнарын арттыруга җибәрелә.";

б) 3 пунктның беренче абзацындагы икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

19) 97[1] статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

"Агымдагы финанс елының беренче кварталында, ярты еллыгында һәм тугыз аенда Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең барышы турында Татарстан Республикасы Хисап палатасының квартал саен мәгълүматы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына җибәрелә һәм, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына чыгарылырга мөмкин.";

20) 97[4] статьяның 2[1] пунктындагы дүртенче абзацында "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты" сүзләрен "Бюджет комитеты" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 63 пунктындагы унтугызынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяда:

а) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 8 пунктның икенче абзацында "2008 – 2009 елларга" сүзләрен "2008 – 2012 елларга" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

"10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында үзенә Россия Федерациясе бюджет законнары нигезләмәләрен исәпкә алып ачылган счетта Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыларның вакытлыча эш итүенә керә торган акчалар белән операцияләр башкару турында карар кабул итәргә хокуклы, күрсәтелгән операцияләр Татарстан Республикасының бюджет акчаларын алучыларга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ачылган шәхси счетларда чагылдырыла.".

**3 статья**

"Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләрен үз көчләрен югалткан дип тану турында" 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп, үзгәреш кертергә:

"2013 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының, шулай ук муниципаль бурычның иң югары чиге әлеге пунктта күрсәтелгән шартларны үтәгән килеш билгеләнә.".

**4 статья**

2011 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^4$ статьясындагы 3 пунктының һәм 4 пунктындагы беренче абзацының гамәли көче Россия Федерациясенең икътисад тармакларына, хезмәт базарына һәм социаль өлкә тармакларына ярдәм итү буенча, халыкны социаль тәэмин итү буенча өстәмә чараларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә торган карарлар буенча җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә карата федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда кулланылмый дип билгеләргә.

**5 статья**

Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) 2011 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләренең эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пункты ("Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) нигезендә субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла;

2) 2012 елның 1 гыйнварыннан түләүле хезмәт күрсәтүләрдән һәм керем китерә торган бүтән эшчәнлектән Татарстан Республикасы казна учреждениеләре тарафыннан алынган керемнәр Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә.

2012 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы казна учреждениесе Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге һәм шушы учреждениенең оператив идарәсенә тапшырылган мөлкәтне арендага тапшырудан үзе алган керемнәрне һәм түләүле хезмәт күрсәтүләрдән килгән акчаларны, физик һәм юридик затлардан

алынган кире кайтарылмый торган кертемнәрне, шул исәптән иреклe иганәләрне, керемнәр китерә торган бүтән эшчәнлектән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең документы (генераль рөхсәте) нигезендә кулланырга хокуклы.

**6 статья**

1 статьядагы 1, 5, 6 пунктларның, 9 пункттагы "а" пунктчасының, 10 пункттагы "б", "в" һәм "г" пунктчаларының, 12 пунктның, 2 статьядагы 1 пунктның, 2 пункттагы 2008, 2009 һәм 2010 елларга күрсәтелгән өлешендә "б" һәм "в" пунктчаларының, 3 һәм 4 статьяларның нигезләмәләре рәсми басылып чыккан көненнән үз көчләренә керәләр һәм 2010 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылалар.

1 статьядагы 2, 3, 4, 7, 8 пунктларның, 9 пункттагы "б" пунктчасының, 10 пункттагы "а", "д" һәм "е" пунктчаларының, 11 пунктның, 2 статьядагы 2 пунктның, 5 статьяның нигезләмәләре 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көчләренә керәләр.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 5 июле
№ 52-ТРЗ